ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«29» апрель 2022 ел № 60-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган велоузыш үткәрү турында

Үсеп килүче буында патриотизм, туган якка мәхәббәт хисләре тәрбияләү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган чаралар үткәрүгә бәйле рәвештә:

1. 2022 елның 7 маенда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган, гомуми белем бирү учреждениеләренең өлкән сыйныф укучылары һәм яшьләр катнашында Әгерҗе-Яңавыл-Әгерҗе маршруты буенча велоузыш үткәрергә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына (В.Г. Сафиуллинага) Велоузышта катнашучы мәктәп укучыларының исемлекләрен (100дән артык булмаган кеше) әзерләргә, Әгерҗедәге Мәңгелек ут янында почетлы каравыл оештырырга, 100 укучыга смета әзерләргә, Яңавыл авылыннан тауга менү программасын эшләргә, Яңавыл авылына старт урынына һәм кире Әгерҗегә кадәр мәктәп автобуслар белән велоузышта катнашучыларны алып баруны һәм ГСМ бирүне оештырырга.

3. «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә (Р.Э. Ниязовка) Әгерҗе шәһәренең «Администрация» бинасы территориясендә урнашкан мәйданны күрсәтелгән чарага әзерләү эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә (М.С. Салиховка), Тирсә (И.Б. Гыйззәтуллинга), Иж-Бубый (Р.Р. Ваһаповка) авыл җирлекләре башлыкларына һәйкәлне, стеланы тиешле хәлгә китерергә; велоузышта катнашучылар белән митинглар оештырырга, велоузыш көнендә веноклар салырга, велоузыш вакытында велосипедта йөрүдә катнашучыларның чәй эчүен оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директорына (И.И.Чуковка) велоузышта катнашучыларны старт алган урынга - Янга-Аул авылына һәм кире Әгерҗе шәһәренә илтүне оештырырга.

6. «Строй-Гигант» ҖЧҖгә (Т.С.Агаҗанянга), «Мир-Строй» ҖЧҖгә (А.Ш.Ибраһимовка), «Стройград» СК" ҖЧҖгә (М.А.Ситдыйковка) велоузыш старт алган урынга - Янга-Аул авылына һәм кире Әгерҗе шәһәренә, Сарсак-Омга авылына кадәр велосипедларны (Камаз прицеп белән) илтүне тәэмин итәргә киңәш итәргә.

7. Әгерҗе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең ЮХИДИ бүлекчәсенә (И.Р.Гатинга), Әгерҗе районында «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУнең Чаллы шәһәре территориаль идарәсен профилактикалау бүлегенә (Р.В. Тимкинага) тәкъдим итәргә Әгерҗе шәһәре-Яңавыл - Тирсә авылы-Мордыбый-Иж-Бәйки авылы-Әгерҗе шәһәре маршруты буенча хәрәкәт иткәндә велоузышта катнашучыларның юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы һәм Әгерҗе шәһәре учреждениеләре, предприятиеләре, оешмалары җитәкчеләренә (милек рәвешенә бәйсез рәвештә) һәм Яңа Бәзәкә (М.С. Салиховка), Тирсә (И.Б. Гыйззәтуллинга), Иж-Бубый (Р.Р. Ваһаповка) авыл җирлекләре башлыкларына велосипедчылар колоннасының хәрәкәт маршруты буенча велоузышта катнашучыларны каршы алуны оештырырга тәкъдим итәргә.

9. «Әгерҗе ЦКС» МБУК директоры (О.В.Михайловага) Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы (М.С. Салиховка) белән берлектә Яңавыл авылында һәм Әгерҗе шәһәренең «Администрация» бинасы территориясендә урнашкан мәйданда велоузышта катнашучылар белән Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган чара оештырырга.

10. "Әгерҗе үзәк район хастаханәсе" ДАССУ баш табибына (Э.В. Овчиниковага) велосипедчылар колоннасын медицина хезмәткәре белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

11. РФ Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенә чараны үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

12. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлегенә (Т.С. Сергеевага) яшьләр арасында велоузышта катнашучыларның исемлекләрен әзерләргә һәм велосипедлар йөрүне велоузыш башланган урынга (50дән артык булмаган кеше) алып баруны оештырырга.

13. 2022 елның 7 маенда Бөек Җиңүнең 77 еллыгына багышланган Велоузыш-2022 оештыру өчен чыгымнар сметасын расларга (кушымта итеп бирелә).

14. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э.Акбашев**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетынын
29.04.2022 № 60-р
карары белән расланган

***2022 елның 7 маенда Бөек Җиңүнең 77 еллыгына багышланган «Велоузыш - 2022» уздыру өчен чыгымнар сметасы***

| № | Чыгымнар атамасы | Исәбе | 1 кешегә бәясе (сум) | Гомуми сумма (сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Камыр ризыклары | 120 | 6 руб. | 720 сум. |
| 2. | чәй | 120 | 8 руб. | 960 сум. |
| 3. | Бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба | 120 | 2.50 руб. | 300 сум. |
| 4. | Яңгырдан саклаучы плащ | 120 | 150 руб. | 18000 сум |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **19980** сум |